# ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

**Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының Федоровский авыл җирлегенең Федоровский авылында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында**

**29 ноябрь, 2020 ел** **№ 1**

2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирлеүзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә 2020 елның 25 нчы ноябрендә 7 сәг 30 минутат , 2020 елның 26 нчы ноябрендә 7 сәг 00 минутта, 2020 елның 27 нче ноябрендә 18 сәг 30 минутта, 2020 елның 28 нче ноябрендә 18 сәг 30 минутта, 2020 елның 29 нчы ноябрендә 14 сәг 00 минутта булган гражданнар җыеннары нәтиҗәләре белән «Сез 2021 елда яшәү урыны буенча Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының Федоровский авыл җирлеге территориясендә теркәлгән һәм даими яшәүче балигъ булган һәр яшәүчедән 500 (биш йөз) сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча хәл итүгә юнәлдерү белән килешәсезме?” соравы буенча гражданнар җыенының беркетмәсе төзелде:

- җәй көне авыл территориясен чаптыру;
- рөхсәтсез чүплекләрне бетерү;
- коены ремонтлау һәм әйләнә-тирәдәге территорияне төзекләндерү;
- Бөек Ватан сугышы ветераннарына куелган һәйкәлне төзекләндерү;
- Федоровский авылындагы юлларны норматив хәлгә китерү;
- җирлекнең торак пунктлары чикләрендә автомобиль юлларын карап тору.

Экономия барлыкка килгән очракта, акчаны аерым мәсьәләләр буенча Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Федоровский авыл җирлеге Башкарма комитетына җыенда билгеләнгән башка мәсьәләләрне хәл итү өчен кулланырга рөхсәт итәргә.»

«РИЗА» «КАРШЫ».

Гражданнар җыенының нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:

Сайлау хокукына ия җыенда катнашучылар исемлегенә гражданнар җыенында катнашучы 522 кеше кертелгән, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар саны -278, бу 53 % тәшкил итә.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучылар түбәндәгечә бүленде:

«Риза» позициясе өчен гражданнар җыенында 271 катнашучы тавыш бирде; «Каршы» позициясе өчен җыенның 7 катнашучысы тавыш бирде.

Бәян ителгәннәр нигезендә гражданнар җыены хәл итте:

1. Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының Федоровский авыл җирлегенең Федоровский авылында гражданнар җыенын узган дип, гражданнар җыены нәтиҗәләрен  дөрес дип танырга.

2. «Сез 2021 елда Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының Федоровский авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны һәм даими яшәүче балигъ булган һәр яшәүчедән 500 (биш йөз) сумм күләмендә үзара салым кертүгә һәм җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча хәл итүгә юнәлдерү белән килешәсезме?

- җәй көне авыл территориясен чаптыру;
- рөхсәтсез чүплекләрне бетерү;
- коены ремонтлау һәм әйләнә-тирәдәге территорияне төзекләндерү;
- Бөек Ватан сугышы ветераннарына куелган һәйкәлне төзекләндерү;
- Федоровский авылындагы юлларны норматив хәлгә китерү;
- җирлекнең торак пунктлары чикләрендә автомобиль юлларын карап тору.»

мәсьәләсе буенча карарны кабул ителгән дип санарга.

Экономия барлыкка килгән очракта, акчаны аерым мәсьәләләр буенча Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Федоровский авыл җирлеге Башкарма комитетына җыенда билгеләнгән башка мәсьәләләрне хәл итү өчен кулланырга рөхсәт итәргә.»

3. Әлеге карарны мәгъулүмат стендларында,Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының Федоровский авыл җирлегенең рәсми сайтында һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгъулүмат рәсми порталында урнаштыру юлы белән бастырып чыгарырга.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен юлларга.

Гражданнар җыенында рәислек иткән,
Федоровский авыл җирлеге Башлыгы  Ф.Ф.Зәйнуллин